**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 30 апрелендәге 1324 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 5 августындагы 7098 номерлы «Бинаны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану буенча шәһәр ведомствоара комиссиясе турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитетында кадрлар үзгәрүгә бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 5 августындагы 7098 номерлы «Бинаны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану буенча шәһәр ведомствоара комиссиясе турында»гы карарының 1 пунктына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 25 ноябрендәге 10198 номерлы, 2014 елның 19 декабрендәге 7334 номерлы, 2015 елның 23 сентябрендәге 3528 номерлы, 2015 елның 26 ноябрендәге 4116 номерлы, 2016 елның 12 маендагы 1983 номерлы, 2016 елның 17 октябрендәге 4162 номерлы, 2016 елның 7 ноябрендәге 4560 номерлы, 2018 елның 19 июлендәге 4092 номерлы, 2018 елның 5 сентябрендәге 4817 номерлы, 2018 елның 18 октябрендәге 5449 номерлы, 2019 елның 24 гыйнварындагы 236 номерлы, 2019 елның 30 декабрендәге 4715 номерлы, 2020 елның 28 августындагы 2330 номерлы, 2022 елның 21 мартындагы 799 номерлы, 2022 елның 9 августындагы 2634 номерлы, 2022 елның 16 декабрендәге 4393 номерлы, 2023 елның 19 маендагы 1424 номерлы, 2024 елның 13 февралендәге 492 номерлы, 2024 елның 2 июлендәге 2812 номерлы, 2024 елның 7 августындагы 3271 номерлы, 2024 елның 30 сентябрендәге 4088 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. бинаны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә

тиеш дип тану буенча шәһәр ведомствоара комиссиясе составына Казан шәһәре Башкарма комитетының шәһәр төзелеше рөхсәтләре идарәсенең шәһәр төзелеше өлкәсендә гамәлдәге законнарны үтәүне тәэмин итү бүлеге башлыгы Н.Ф.Хафизовны һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенең юридик бүлеге башлыгы урынбасары Д.Р.Сираҗетдиновны комиссия әгъзалары сыйфатында кертергә;

1.2. 3 пунктта «Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләренә (Ф.В.Нурмөхәммәтов, А.И.Салихов, С.А.Миронов, Р.Р.Фәтхетдинов)» сүзләрен «Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләренә (Р.Х.Шәмсетдинов, А.И.Салихов, В.В.Жаворонков, Р.Р.Фәтхетдинов)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә. Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**